**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Сугышлы авыл җирлеге**
**Юлтимер авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2020 елның 20 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге **Юлтимер** авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге **Юлтимер** авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, I төркем инвалидлары, Беек Ватан сугышы ветераннары, кендезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

1) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру ечен шартлар тудыру;

– Юлтимер авыл мәдәният йорты территориясендә яңа балалар бакчасы коймасы төзү;

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә;

– Юлтимер авылында Расыйх чишмәсе һәм Кадехнур чишмәсенә яңа коймаларын төзү;

3) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә

– Юлтимер авылында су линияләренең өзеклекләрен бетерү эшләрен оештыру;

4) җирлек чикләрендә халыкны электр белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә:

- Юлтимер авылында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

5) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:

- Юлтимер авылында юлларны кардан чистарту ( Совет ур., Игтисамовлар ур.);

6) торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү

– Совет урамы башында янгын гидранты урнаштыру.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Сугышлыавыл җирлеге» башлыгы А.П.Зыятдинова

ИНН 1625000408
КПП 164901001